| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| 16.06.2017 | | № 92 |

2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2020 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү" дәүләт программасын раслау турында" 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында эчке һәм күчмә туристлыкны үстерү, яшьләрне инновацияле туристлык проектларын тормышка ашыруга җәлеп итү, Татарстан Республикасының өстенлекле туристлык үзәкләрен үстерү максатларында боерык бирәм:

1. 2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (Е.Е.Попова) Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшне оештырырга.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча рәис урынбасары А.И. Абдрашитовны җаваплы итеп билгеләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 16.06.2017
№ 92 боерыгы белән
расланды

**2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсын үткәрү турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрүнең тәртибен, Конкурста катнашучыларга, конкурс проектларына һәм аларны Конкурска тапшыру тәртибенә карата таләпләрне, шулай ук Конкурс үткәрү вакытларын билгели.

1.2. Конкурсның максаты булып яшьләрне Татарстан Республикасының туристлык үзәкләрен үстерү һәм алга этәрү буенча инновацияле туристлык проектларын тормышка ашыруга җәлеп итү, туган төбәкнең туристлык ресурслары, аның мәдәни һәм экологик ядкәрләре турында яшьләрнең хәбәрдарлыгын арттыру аша патриотлык хисен тәрбияләү тора.

1.3. Конкурсның төп бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясенә туристларны җәлеп итү буенча туристлык, өлкә һәм мәдәни юнәлешле проектларны булдыру һәм пропагандалау;

Татарстан Республикасында эчке һәм күчмә туристлыкны үстерү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм туристлык өлкәсенә җәлеп итү.

1.4. Конкурсның оештыручысы булып Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора.

1.5. Конкурсның приз фондын финанслау 2017 елга Дәүләт комитетының керемнәр һәм чыгымнар буенча җыелма сметасында каралган акчалар хисабыннан гамәлгә ашырыла.

1.6. Әлеге Нигезләмә конкурс чаралары тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.

## 2. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Конкурста Татарстан Республикасының югары, урта һөнәри белем бирүче белем йортлары студентлары исәбендәге затлар (белем бирү йортының профиленә һәм укыту формасына бәйсез рәвештә), гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, эшләүче яшьләр, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яшьләрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнаша.

2.3. Конкурста катнашуга проектларны алга этәрү оешмалар тарафыннан да, белем (гомуми белем бирү) йортлары тарафыннан да, дәгъва кылучыларның үзләре тарафыннан да гамәлгә ашырыла. Конкурста күмәк башкарылган эшләрнең катнаштырылуы рөхсәт ителә.

Конкурста катнашу бер яисә берничә номинациядә (теләккә карап) кабул ителә.

2.4. Конкурста 14 яшьтән 25 яшькәчә булган (25 яшен тутырган) физик затлар катнаша.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс 2017 елның 1 августыннан 20 декабренә кадәр бер этапта үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Дәүләт комитетының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) конкурс проектларын кабул итә башлаганчыга кадәр 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.2. Дәүләт комитетына конкурс проектларын тапшыру чоры – 2017 елның 1 августыннан 1 ноябренә кадәр.

Конкурс проектлары кулдан кулга тапшырыла яисә түбәндәге адрес буенча почта аша җибәрелә: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., М.Горький ур., 19 й. (кабинет № 1). Почта аша җибәргәндә конкурс проекты шулай ук флеш-җайланмага да салына.

Конкурс проектының электрон версиясе Конкурсны оештыручының электрон адресларына кабатлап җибәрелә – Olga.Neumoina@tatar.ru, Aysylu.Saypeeva@tatar.ru

3.3. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктчасында күрсәтелгән, үз вакытында тапшырылган, эчтәлеге һәм рәсмиләштерелеше шушы Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс проектлары Конкурста катнашуга кертелә. Конкурска Татарстан Республикасының билгеле бер туристлык юнәлешенә, туристлык үзәгенә, туристлык индустриясе объектына яисә тулаем туристлык комплексына бәйле булган, республиканың туристлык продуктын булдыруга, үстерүгә яисә камилләштерүгә, Татарстан Республикасына Россиянең һәм чит илләрнең туристларын җәлеп итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрне үз эченә алган конкурс проектлары тапшырыла.

3.4. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) Туристлык төрләре буенча иң яхшы маршрут – түбәндәге бүлекләр буенча:

тарихи мирас маршруты;

авылча туристлык маршруты;

этнотуристлык маршруты;
актив туристлык һәм ял маршруты;
сәнәгать туристлыгы маршруты;
гастрономик туристлык маршруты.

2) Иң яхшы видео-экскурсия.

3) Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект.

3.5. Һәр номинация буенча Конкурс катнашучылар яшенә карата ике төркемдә үткәрелә:

14 яшьтән башлап 18 яшькәчә булган катнашучыларның конкурс проектлары;

19 яшьтән башлап 25 яшькәчә булган катнашучыларның конкурс проектлары.

"Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты" номинациясендә конкурс проекты күрсәтү объектларын сурәтләп, маршрутның карта-схемасы, экскурсиянең контроль тексты һәм "экскурсияче портфеле" белән, экскурсия маршрутының үзен турыдан-туры үз эченә ала.

Экскурсиянең маршруты экскурсия төркеменә хәрәкәт итү өчен иң уңайлы юлдан гыйбарәт. Маршрут әлеге экскурсия өчен объектларны карауның иң дөрес эзлеклелегенә, төркемне урнаштыру өчен мәйданчыклар булу-булмауга карап төзелә. Маршрут бурычларының берсе – экскурсия темасын булдыра алганча тулы итеп ачарга ярдәм итү. Маршрутны төзүгә төп таләпләр – объектларны логистик эзлеклелек буенча күрсәтүне оештыру һәм теманы ачу өчен тамашачылык нигезен тәэмин итү.

Экскурсиянең контроль тексты – экскурсантларга җиткерелә торган мәгълүматларның фәнни, актуальләштерелгән эчтәлеген үз эченә ала торган технологик документ. Контроль текст нигезендә экскурсияче экскурсиячәнең үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен чагылдыра торган һәм билгеле бер экскурсантларның мәнфәгатьләренә җавап бирә торган аерым текст төзи (чыганак: ГОСТ Р 50681-2010: Туристлык хезмәтләре. Туристлык хезмәтләрен проектлау).

Экскурсиясе портфеле – экскурсияче тарафыннан экскурсияне үткәрү барышында кулланыла торган мәгълүмати материаллар комплектының (фотолар, документларның күчермәләре, география карталары, схемалар, картина репродукцияләре һ.б.) шартлыча аталышы (чыганак: ГОСТ Р 50681-2010: Туристлык хезмәтләре. Туристлык хезмәтләрен проектлау).

"Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект" номинациясенә, максатларны һәм бурычларны, максатларга ирешү стратегияләрен һәм механизмнарын, чараларның планын/графигын, планлаштырылган нәтиҗәләрен, үсеш перспективаларын күрсәтеп, туристларны җәлеп итү элементы буларак нинди

дә булса чараны (мәдәни, спорт, тарихи, этнографик һәм эшлекле характерда) сурәтләүгә бәйле конкурс проекты тапшырыла.

3.6. Конкурска түбәндәге материаллар тапшырыла:

билгеләнгән формалы анкета-заявка (шушы Нигезләмәгә 1 нче, 2 нче кушымталар);

проект документлары, түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

басма материаллар: Word форматындагы текст (шрифт зурлыгы – 12, юллар арасындагы аралык – берле), текст күләме – 30 000 аралыклы басма билгесенә кадәр;

фотоматериаллар: PDF/JPG форматында (иң күбе – 15 фото);

CD/DVD дискларда һәм флеш-җайланмаларда аудио һәм видеоматериаллар.

Басма материалар кәгазьдә һәм электрон рәвешендә тапшырыла.

Тапшырылган документларның барлык текстлары да авторның исеменнән, фамилиясеннән һәм белем бирү йортының аталышыннан башланырга тиеш.

Конкурс материаллары теләсә нинди чит телдә (ш.и. татар телендә) бары тик рус теленә тәрҗемәсе булган очракта гына тапшырыла ала.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән датадан соң тапшырылган конкурс материаллары каралмый һәм Конкурста катнашуга кертелми.

3.8. Конкурска җибәрелгән барлык материаллар да кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Конкурста сайлап алу тәртибе

4.1. Килгән конкурс проектларын бәяләү максатында Дәүләт комитеты тарафыннан Конкурс комиссиясе (алга таба –Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте, туристлык һәм иҗтимагый оешмалары, фәнни бергәлек вәкилләреннән Комиссия рәисе җитәкчелегендә, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатип катнашында 12 кешелек составта раслана.

4.3. Комиссиянең эшенә рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда аның вазыйфалары урынбасарына йөкләнә. Өстәмә рәвештә экспертлар җәлеп итү хокукын Комиссия үз ихтыярында калдыра. Конкурс нәтиҗәләре турында шәхсән кызыксынган затлар Комиссия әгъзалары була алмыйлар.

4.4. Комиссиянең эше утырышта гамәлгә ашырыла. Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш тулы хокуклы булып санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне үти:

шушы Нигезләмәнең 3.6-3.8 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, материалларны кабул итә һәм терки, һәм аларның саклануын тәэмин итә;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә рәсмиләштерә.

4.6. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан әгъзалар тарафыннан бирелгән тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче һәм җаваплы сәркатип кул куя. Тавышлар саны тигез булганда, рәиснең тавышы хәл иткеч булып санала.

4.7. Конкурста катнашучы Конкурс нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, ул Конкурс комиссиясенә апелляция бирү хокукына ия.

Апелляция язмача рәвештә ирекле формада Комиссия рәисе исеменә Комиссия беркетмәсе Дәүләт комитеты сайтында бастырып чыгарылганнан соң өч эш көне эчендә тапшырыла. Ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында тапшырылган апелляцияләр Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

Комиссия әгъзалары апелляцияләр килү чоры тәмамланган көннән соңгы дүрт эш көне эчендә аларны карап тикшерәләр һәм коллегиаль рәвештә фикер алышалар. Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш туплау нигезендә кабул ителә һәм Комиссиянең катнашкан әгъзалары күпчелекне тәшкил иткәндә, легитимлы булып танылa. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәл итүле була. Комиссиянең җаваплы сәркатибе Комиссия карары нигезендә беркетмә рәсмиләштерә. Беркетмәдә Комиссиянең һәр әгъзасының фикере һәм гомуми йомгак күрсәтелә:

апелляцияне канәгатьләндермәү һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмәгә Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатип кул куя.

Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары иң соңгысы була, ул яңадан каралмый һәм суд тәртибендә шикаять кылынырга мөмкин.

## 5. Конкурста җиңүчеләр һәм дипломантлар

5.1. Конкурста җиңүчеләр һәм дипломантлар Конкурс комиссиясе утырышында билгеләнә. Комиссия Конкурста катнашучылар каршысында бәяләрне нигезләми.

5.2. Конкурсның һәр номинациясендә катнашучыларның яшенә карата һәр ике төркемнән өч җиңүче билгеләнә – 1, 2, 3 урын. Конкурсның һәр номинациясендә җиңүчеләр Дәүләт комитетының махсус дипломнары һәм истәлекле призлары белән бүләкләнә.

5.3. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү 10 баллы шкала буенча катнашучыларның конкурс проектларының сыйфатын бәяләү критерийларына нигезләнеп башкарыла (шушы Нигезләмәгә 3 нче кушымта).

5.4. Һәр критерий буенча Конкурс комиссиясе әгъзасы ун баллы шкала буенча билге куя. Һәр критерий буенча билгеләрнең суммасы Конкурста катнашучыга гомуми билгене бирә.

5.5. Заявка составындагы материалларны эшкәрткәндә һәм анализлаганда, аларның объектив булу-булмавын бәяләгәндә Конкурс комиссиясе әгъзалары ун баллы шкала буенча бәяләү процессында үзара ышану, шәхсән җаваплы һәм таләпчән булу принципларыннан чыгып эш итә (1 балл – иң түбән билге, 10 балл – иң югары билге).

5.6. Конкурс йомгаклары турында карар Конкурс комиссиясе тарафыннан балларның гомуми суммасы буенча һәм шушы Нигезләмәнең 4.6 пунктына туры китереп кабул ителә.

5.7. Конкурс комиссиясе, әгәр дә Конкурска Конкурс таләпләренә тулы дәрәҗәдә җавап бирә торган конкурс проектлары тапшырылмаса, бер яисә берничә призлы урынны бирмәү хокукын үз ихтыярында калдыра.

5.8. Конкурсны оештыручы белән алдан килештереп, кызыксынган оешмалар тарафыннан үткәрелүче Конкурс кысаларында махсус казанышлар өчен катнашучыларга өстәмә призлар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.9. Конкурс комиссиясенең карары буенча өстәмә номинацияләрдә бүләкләү башкарыла.

5.10. Конкурс нәтиҗәләре Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе нигезендә, аңа имза салынган көннән соңгы эш көннәрендә исәпләнүче 3 көнлек чорда Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.11. Конкурс йомгаклары Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыруның Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) оештырыла торган тантанасында 2017 елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча әйтелә. Конкурс йомгаклары турында игълан Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасы үткәрелгән көнне бастырып чыгарыла.

5.12. Конкурсны оештыручы түбәндәгеләрне үз ихтыярында калдыра:

тапшырылган конкурс проектларын үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару хокукын;

материалларны челтәрләрле теле- һәм радиокомпанияләрнең эфирларында урнаштыру хокукын;

Конкурста җиңүчеләрнең конкурс проектларын Дәүләт комитетының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) катнашучының авторлыгына сылтама белән бастырып чыгару хокукын.

5.13. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс проектларын җибәрү факты белән шушы Нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулысынча һәм берсүзсез риза булуларын раслыйлар.

5.14. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс проектларын җибәрү факты белән үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкларын раслыйлар.

2017 елда "Чыганакларга сәяхәт"
VIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

**2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсында катнашучыдан**
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинация: "Туристлык төрләре буенча иң яхшы маршрут"**
**Бүлек** (кирәклесен аерып чыгарырга)

- тарихи мирас маршруты
- авылча туристлык маршруты
- этнотуристлык маршруты
- актив туристлык һәм ял маршруты
- сәнәгать туристлыгы маршруты
- гастрономик туристлык маршруты

1. **Тутыру датасы "_____" "_____________" 2017 ел.**

2. **Катнашучының Ф.И.А. (тулысынча)**
____________________________________________________________
____________________________________________________________

3. **Яше** _______________________________

4. **Җитәкчесенең Ф.И.А.**
____________________________________________________________
____________________________________________________________

5. **Катнашучының/белем бирү йортының яшәү/урнашу адресы:**
____________________________________________________________
____________________________________________________________

6. **Элемтә телефоннары, электрон почтасы** (e-mail)______________________________
____________________________________________________________

7. **Катнашучы турында белешмәләр:**
- белем бирү йортының/эш урынының һ.б. аталышы (тулысынча)
____________________________________________________________
____________________________________________________________
- өстәмә башка мәгълүматлар _______________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

8. **Эшнең аталышы, кыскача аннотациясе**
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

9. **Конкурс комиссиясе йомгаклары**

2017 елда "Чыганакларга сәяхәт"
VIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

**2017 елда "Чыганакларга сәяхәт" VIII республика конкурсында катнашучыдан**
**АНКЕТА-ЗАЯВКА**

**Номинациясе** (кирәклесен аерып чыгарырга)

- o Иң яхшы видео-экскурсия
- o Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект

| |
|---|
| **1. Тутыру датасы "_____" "_____________" 2017 ел.**<br><br>2. **Катнашучының Ф.И.А. (тулысынча)**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>3. **Яше** ______________________________<br><br>**4. Җитәкчесенең Ф.И.А.**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**5. Катнашучының/белем бирү йортының яшәү/урнашу адресы:**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**6. Элемтә телефоннары, электрон почтасы** (e-mail)__________________________<br>________________________________________<br><br>**7. Катнашучы турында белешмәләр:**<br>- белем бирү йортының/эш урынының һ.б. аталышы (тулысынча)<br>________________________________________<br>________________________________________<br>________________________________________<br>- өстәмә башка мәгълүматлар ______________________________<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**8. Эшнең аталышы, кыскача аннотациясе**<br>________________________________________<br>________________________________________<br>________________________________________<br>________________________________________<br>________________________________________ |
| **9. Конкурс комиссиясе йомгаклары** |

2017 елда "Чыганакларга сәяхәт"
VIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Катнашучыларның конкурс проектларының сыйфатын бәяләү критерийлары**

| Критерийның аталышы | Баллар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Белдерелгән номинациянең туры килүе | | | | | | | | | | |
| Иҗади якын килү һәм эчтәлегенең маҗаралы булуы | | | | | | | | | | |
| Материалны бәян итү стиле, теле (аныклыгы, мантыйклыгы, лексикасы, грамматикасы) | | | | | | | | | | |
| Туристлык төшенчәләренә һәм терминнарына ия булуы | | | | | | | | | | |
| Тапшырылган материалның тикшеренү тирәнлеге | | | | | | | | | | |
| Конкурс проектының Конкурс турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән булуы | | | | | | | | | | |
| * "Экскурсияче портфеле" булу | | | | | | | | | | |
| * Экскурсиянең контроль тексты булу | | | | | | | | | | |
| * Маршрутның карта-схемасы булу | | | | | | | | | | |
| ** Җентекле икътисадый нигезләмә | | | | | | | | | | |
| *** Техник яктан тормышка ашыру (видеоязманың сыйфаты, видеороликны монтажлау, башкару катлаулылыгы) | | | | | | | | | | |

* "Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты" номинациясендә бәяләнә

** "Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект" номинациясендә бәяләнә

*** "Иң яхшы видео-экскурсия" номинациясендә бәяләнә